КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2022 ел, 2 март г.Казань № 6-425

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 59 статьясындагы 13 өлеше нигезендә урта гомуми белем бирүнең мәгариф программаларын үзләштергән укучыларның дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

2022 елда бердәм дәүләт имтиханын, дәүләт чыгарылыш имтиханын үткәрүне тәэмин итәргә;

2022 елда «Туган тел (татар теле)» һәм «Туган әдәбият (татар әдәбияты)» предметларын өйрәнгән һәм бу фәннәр буенча имтихан бирүне сайлап алган укучылар өчен туган тел (татар теле) һәм туган әдәбият (татар әдәбияты) буенча бердәм республика имтиханын үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына имтиханнар үткәрү пунктларында медицина персоналының кизү торуын оештыруда ярдәм күрсәтергә.

3. Бердәм дәүләт имтиханын, дәүләт чыгарылыш имтиханын һәм бердәм республика имтиханын үткәрү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2021 елның 25 ноябрендәге 86-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы» ведомствосы буенча каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, мәгариф өлкәсендә идарә итүне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары белән берлектә, имтиханнар үткәрү пунктлары янындагы территорияләрдә иҗтимагый тәртипне саклауда һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итүдә кирәкле ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин